КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 4 май г.Казань № 304

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитен саклау, табигать ресурсларын торгызу һәм файдалану» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 28 декабрь, 1083 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитен саклау, табигать ресурсларын торгызу һәм файдалану» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитен саклау, табигать ресурсларын торгызу һәм файдалану» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 28 декабрь, 1083 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 21 июль, 521 нче; 2014 ел, 24 ноябрь, 904 нче; 2014 ел, 6 декабрь, 950 нче; 2015 ел, 6 май, 329 нчы; 2015 ел, 30 ноябрь, 906 нчы; 2015 ел, 1 декабрь, 910 нчы; 2016 ел, 9 июнь, 383 нче; 2016 ел, 23 декабрь, 980 нче; 2017 ел, 27 февраль, 117 нче; 2018 ел, 5 май, 326 нчы; 2018 ел, 27 сентябрь, 866 нчы; 2019 ел, 27 июль, 628 нче; 2020 ел, 8 июнь, 472 нче; 2020 ел, 12 ноябрь, 1013 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитен саклау, табигать ресурсларын торгызу һәм файдалану» дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программа паспортында:

«Программаны финанслау күләме һәм чыганаклары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Программаны финанслау күләме һәм чыганаклары

2014 – 2024 елларда Программаны финанслауның гомуми күләме 16 074 715,3 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:
билгеләнгән тәртиптә бүлеп бирелә торган федераль бюджет акчасы – 3 662 767,1 мең сум;
Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 9 665 568,9 мең сум;
күздә тотыла торган җирле бюджетлар акчасы – 2 746 379,3 мең сум, шул исәптән:
I этап – 8 051 670,7 мең сум, шул исәптән:
билгеләнгән тәртиптә бүлеп бирелә торган федераль бюджет акчасы – 787 237,4 мең сум;
Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 5 735 086,9 мең сум;
җирле бюджетлар акчасы – 1 529 346,4 мең сум, шул исәптән:

(мең сум)

| Финанслау чыганагы | Барлык акча | Еллар буенча финанслау күләмнәре (I этап) | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел |
| Федераль бюджет | 787 237,4 | 109 110,2 | 72 825,8 | 89 282,5 | 348 873,2 | 70 035,4 | 97 110,3 |
| Татарстан Республикасы бюджеты | 5 735 086,9 | 1 216 164,0 | 697 012,1 | 883 611,8 | 1 194 626,9 | 742 237,7 | 1 001 434,4 |
| Җирле бюджетлар | 1 529 346,4 | 307 600,0 | 290 707,0 | 230 392,0 | 198 628,2 | 274 544,9 | 227 474,3 |
| Барлыгы | 8 051 670,7 | 1 632 874,2 | 1 060 544,9 | 1 203 286,3 | 1 742 899,5 | 1 086 818,0 | 1 326 019,0 |

II этап – 8 023 044,6 мең сум*, шул исәптән:
билгеләнгән тәртиптә бүлеп бирелә торган федераль бюджет акчасы – 2 875 529,7 мең сум;
Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 3 930 482,0 мең сум;
күздә тотыла торган җирле бюджетлар акчасы – 1 217 032,9 мең сум, шул исәптән:

(мең сум)

| Финанслау чыганагы | Барлык акча | Еллар буенча финанслау күләмнәре (II этап) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел |
| Федераль бюджет | 2 875 529,7 | 1 347 012,0 | 186 429,0 | 566 963,4 | 729 377,1 | 45 748,2 |
| Татарстан Республикасы бюджеты | 3 930 482,0 | 1 752 734,3 | 732 482,3 | 505 436,5 | 542 514,2 | 397 314,7 |
| Җирле бюджетлар | 1 217 032,9 | 205 296,9 | 252 934,0 | 252 934,0 | 252 934,0 | 252 934,0 |
| Барлыгы | 8 023 044,6 | 3 305 043,2 | 1 171 845,3 | 1 325 333,9 | 1 524 825,3 | 695 996,9 |

*Финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, тиешле бюджетларның мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш»;

«Программаны тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр һәм аның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Программаны тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗә- | Программа чараларын тулы күләмдә тормышка ашыру түбәндәге нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>I этап (2014 – 2019 еллар):<br>2014 елга җирлекләрне яшелләндерү дәрәҗәсен 27 процентка кадәр арттырырга; |

| | |
|---|---|
| ләр һәм аның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | 2019 елга:<br>барлыкка килгән каты коммуналь калдыкларның гомуми саныннан каты коммуналь калдыкларны аерым җыю һәм эшкәртү (сортларга аеру) барышында алынган икенчел ресурслар өлешен 20 процентка кадәр арттырырга;<br>биологик калдыкларны җыю һәм чыгару өчен сатып алынган контейнерлар саны 8 данә тәшкил итәчәк;<br>Татарстан Республикасы территориясендә Куйбышев һәм Түбән Кама сусаклагычлары акваториясендә урнашкан, суга баткан һәм тикшерелгән йөзү чаралары саны – 90 берәмлек;<br>тупланган экологик зыянның бетерелгән объектлары саны – 5 данә;<br>ел саен 1 мең нөсхә тиражы белән «Георесурсы» журналы чыгарылышлары саны – 4 чыгарылыш;<br>Түбән Кама муниципаль районының торак пунктларында төзелгән биологик чистарту корылмалары саны – 3 берәмлек;<br>Татарстан Республикасының Кызыл китабына ел саен кертелгән төрләр саны – 1 берәмлек;<br>Татарстан Республикасының Кызыл китабына ел саен кертелгән, сирәк булуның иң түбән категориясенә күчерелгән төрләр саны – 1 берәмлек;<br>Татарстан Республикасының Кызыл китабыннан ел саен чыгарылган төрләр саны – 1 берәмлек;<br>махсус саклана торган табигать территорияләре мәсьәләләре буенча ел саен чыга торган басмалар саны – кимендә 1 данә;<br>махсус саклана торган табигать территорияләре мәсьәләләре буенча басмалар санын 15 данәгә кадәр җиткерергә;<br>әйләнә-тирә мохит торышы турындагы дөрес мәгълүматтан файдалана алу мөмкинлеге булган Татарстан Республикасы халкы өлешен 0,18 процентка кадәр арттырырга;<br>2018 – 2019 елларга Россия Федерациясе субъектларында Инвестицион климат торышының илкүләм рейтингы күрсәткечләре нигезендә Татарстан Республикасында инвестицион климатны яхшырту чаралары планының («юл картасының») билгеләнгән вакытларда үтәлгән чаралары өлешен 100 процент тәэмин итәргә;<br>төбәк дәүләт экология күзәтчелеге нәтиҗәлелеген 3,8 мең сум күләмендә тәэмин итәргә;<br>Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитне саклау, табигать ресурсларын торгызу һәм алардан файдалану өлкәсендә яңа төзелгән социаль һәм инженерлык инфраструктурасы объектлары саны – 10 берәмлек;<br>Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитне саклау, табигать ресурсларын торгызу һәм алардан файдалану |

| | |
|---|---|
| | өлкәсендә ремонт ясалган социаль һәм инженерлык инфраструктурасы объектлары саны – 3 берәмлек;<br>II этап (2020 – 2024 еллар):<br>2024 елга:<br>әйләнә-тирә мохит торышын күзәтүнең территориаль системасы урнаштырылган муниципаль районнар (шәһәр округлары) саны – 40 берәмлек;<br>атмосфера һавасы пычрануның җыелма исәп-хисапларына кертелгән Татарстан Республикасының эре шәһәрләре саны – 6 берәмлек;<br>әйләнә-тирә мохит сыйфаты буенча эшләнгән һәм гамәлгә кертелгән төбәк нормативлары саны – 40 берәмлек;<br>республикада яшәүчеләрнең гомуми санынннан табигатьне саклау, экология-агарту чараларында катнашучы халык өлешен 35,4 процентка кадәр арттырырга;<br>Татарстан Республикасы халкының гомуми санынннан каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин ителгән халык өлешен 90 процентка кадәр арттырырга;<br>барлыкка килгән каты коммуналь калдыкларның гомуми массасында күмү өчен җибәрелгән, шул исәптән эшкәртелгән (сортларга аерылган) каты коммуналь калдыклар өлешен 99,1 процентка кадәр арттырырга;<br>барлыкка килгән каты коммуналь калдыкларның гомуми массасында эшкәртүгә (сортларга аеруга) җибәрелгән каты коммуналь калдыклар өлешен 40 процентка кадәр арттырырга;<br>барлыкка килгән каты коммуналь калдыкларның гомуми массасында каты коммуналь калдыкларны аерып җыю һәм эшкәртү (сортларга аеру) нәтиҗәсендә аерылган һәм утилизацияләүгә җибәрелгән калдыклар өлешен 0,9 процентка кадәр арттырырга;<br>каты коммуналь калдыкларны аерым туплау һәм җыю өчен җиһазландырылган контейнер мәйданчыклары өлешен 40 процентка кадәр арттырырга;<br>каты коммуналь калдыкларны заманча күмү объектларында урнаштырылган каты коммуналь калдыклар өлешен 100 процентка кадәр арттырырга;<br>тупланган экологик зыянның иң куркыныч объектларын бетерергә, арта бара торган йомгак белән – 2 данә;<br>тупланган экологик зыянның Идел елгасына куркыныч яный торган һәм бетерелгән объектлары саны – 2 берәмлек;<br>куркыныч экзоген геологик процесслар мониторингы белән колачланган Татарстан Республикасы муниципаль районнары санының куркыныч экзоген геологик процессларның тискәре |

| | |
|---|---|
| | йогынтысына дучар булган Татарстан Республикасы муниципаль районнары санына карата нисбәтен 39 процентка кадәр тәэмин итәргә;<br>геологик мохит мониторингы белән колачланган территория мәйданының Татарстан Республикасы территориясенең гомуми мәйданына карата нисбәтен 48,2 процентка кадәр тәэмин итәргә;<br>җир асты суларының расланган запаслары һәм аларның фаразланган ресурслары нисбәтен 43 процентка кадәр тәэмин итәргә;<br>су алу корылмаларының гомуми санында суны исәпкә алу системалары белән җиһазландырылган су алу корылмалары өлешен 96 процентка кадәр арттырырга;<br>елга үзәннәренең чистартылган участоклары озынлыгы – 13,3 км;<br>Татарстан Республикасының гомуми мәйданында барлык дәрәҗәләрдәге махсус саклана торган табигать территорияләре биләгән Татарстан Республикасы мәйданы өлешен 6,8 процентка кадәр арттырырга;<br>Татарстан Республикасының махсус саклана торган табигать территорияләрендә ачыкланган һәм кисәтелгән бозулар саны – ел саен кимендә 690 берәмлек;<br>Татарстан Республикасы территориясендә яши торган аучылык ресурслары төрләренең гомуми санында аучылык ресурслары саны мониторингы алып барыла торган әлеге ресурслар төрләре өлешен 100 процентка кадәр арттырырга;<br>билгеләнгән бозулар фактларының гомуми санында федераль дәүләт аучылык күзәтчелеге өлкәсендә ачыкланган һәм җаваплылыкка тарту турында карарлар чыгарылган бозулар өлешен 90 процентка кадәр арттырырга;<br>стационар чыганаклардан чыга торган пычраткыч матдәләрнең гомуми күләмендә атмосфера һавасын пычрата торган матдәләрнең тотылган һәм зарарсызландырылган өлешен 61 процентка кадәр арттырырга;<br>тикшерелгән автомобильләрнең гомуми санында эшләп чыгарылган газларында пычраткыч матдәләр күп булган автотранспорт чаралары өлешен 6,8 процентка кадәр киметергә;<br>әйләнә-тирә мохитнең торышы, аның пычрануы белән бәйле тискәре күренешләр (тенденцияләр) турындагы фаразлар һәм кисәтүләрнең расланганлыгы өлешен 93 – 95 процентка кадәр тәэмин итәргә;<br>су чыгаруның гомуми күләмендә агып төшә торган суларның пычрак (чистартылмаган) өлешен 11,1 процентка кадәр киметергә; |

| | |
|---|---|
| | рекультивацияләнә торган җирләр өлешен 46 процентка кадәр арттырырга;<br>агып төшә торган суларның гомуми күләмендә агып төшә торган суларның норматив чистартылган өлешен 19,0 процентка кадәр арттырырга;<br>табигатьтән файдалану һәм әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә ачыкланган бозулар санынннан бетерелгән бозулар өлешен кимендә 96 процент дәрәҗәсендә тәэмин итәргә (В.2.5 төркеме күрсәткече);<br>салынган штрафлардан түләтелгән акча өлешен кимендә 70 процент дәрәҗәсендә тәэмин итәргә (В.3.1.37 төркеме күрсәткече);<br>административ җәзаларның гомуми санында кисәтүләр өлешен кимендә 10 процент тәэмин итәргә (В.3.2.9 күрсәткече);<br>бирелгән лицензияләр санының файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, разведкалау һәм чыгару максаты белән җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы алу турындагы гаризаларның карап тикшерелгән санына карата нисбәтен 96 процентка кадәр тәэмин итәргә»; |

I бүлектәге «Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре тарафыннан табигатьне саклау чараларын тормышка ашыру» бүлекчәсенең өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1 этапта (2014 – 2019 еллар) тиешле территорияләрдә табигатьне саклау чараларын тормышка ашыруга юнәлдерелгән җирле бюджетлардан финанс чараларының гомуми күләме 1 529 346,4 млн.сум, II этапта (2020 – 2024 еллар) планлаштырыла торган акча күләме 1 217 032,9 млн.сум тәшкил итте.»;

Программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. Программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

2014 – 2024 елларда Программаны финанслауның гомуми күләме 16 074 715,3 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:

билгеләнгән тәртиптә бүлеп бирелә торган федераль бюджет акчасы – 3 662 767,1 мең сум;

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 9 665 568,9 мең сум;

күздә тотыла торган җирле бюджетлар акчасы – 2 746 379,3 мең сум, шул исәптән:

I этап – 8 051 670,7 мең сум, шул исәптән:

билгеләнгән тәртиптә бүлеп бирелә торган федераль бюджет акчасы – 787 237,4 мең сум;

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 5 735 086,9 мең сум;

җирле бюджетлар акчасы – 1 529 346,4 мең сум, шул исәптән:

(мең сум)

| Финанслау чыганагы | Барлык акча | Еллар буенча финанслау күләмнәре (I этап) | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел |
| Федераль бюджет | 787 237,4 | 109 110,2 | 72 825,8 | 89 282,5 | 348 873,2 | 70 035,4 | 97 110,3 |
| Татарстан Республикасы бюджеты | 5 735 086,9 | 1 216 164,0 | 697 012,1 | 883 611,8 | 1 194 626,9 | 742 237,7 | 1 001 434,4 |
| Җирле бюджетлар | 1 529 346,4 | 307 600,0 | 290 707,0 | 230 392,0 | 198 628,2 | 274 544,9 | 227 474,3 |
| Барлыгы | 8 051 670,7 | 1 632 874,2 | 1 060 544,9 | 1 203 286,3 | 1 742 899,5 | 1 086 818,0 | 1 326 019,0 |

II этап – 8 023 044,6 мең сум*, шул исәптән:

билгеләнгән тәртиптә бүлеп бирелә торган федераль бюджет акчасы – 2 875 529,7 мең сум;

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 3 930 482,0 мең сум;

күздә тотыла торган җирле бюджетлар акчасы – 1 217 032,9 мең сум, шул исәптән:

(мең сум)

| Финанслау чыганагы | Барлык акча | Еллар буенча финанслау күләмнәре (II этап) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел |
| Федераль бюджет | 2 875 529,7 | 1 347 012,0 | 186 429,0 | 566 963,4 | 729 377,1 | 45 748,2 |
| Татарстан Республикасы бюджеты | 3 930 482,0 | 1 752 734,3 | 732 482,3 | 505 436,5 | 542 514,2 | 397 314,7 |
| Җирле бюджетлар | 1 217 032,9 | 205 296,9 | 252 934,0 | 252 934,0 | 252 934,0 | 252 934,0 |
| Барлыгы | 8 023 044,6 | 3 305 043,2 | 1 171 845,3 | 1 325 333,9 | 1 524 825,3 | 695 996,9 |

*Финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, тиешле бюджетларның мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.

Ярдәмче программалар яктылыгында Программаны финанслау күләмнәре, финанслау чыганаклары һәм акча белән баш эш итүчеләр турындагы мәгълүмат Программага 2 нче кушымтада китерелә.»;

Программага 1, 2, 4 нче кушымталарны яңа редакциядә (карарга теркәләләр) бәян итәргә;

«Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохите сыйфатын җайга салу» ярдәмче программасында (алга таба – 1 нче ярдәмче программа):

1 нче ярдәмче программа паспортында:

«Еллар буенча бүлеп, 1 нче ярдәмче программаны финанслау күләме» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар буенча бүлеп, 1 нче ярдәмче программаны финанслау күләме | 1 нче ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 823 118,4 мең сум* тәшкил итәчәк, шул исәптән:<br>I этап – Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 563 519,6 мең сум, шулардан:<br>2014 елда – 240 035,3 мең сум; |

| | |
|---|---|
| | 2015 елда – 53 741,1 мең сум;<br>2016 елда – 68 298,5 мең сум;<br>2017 елда – 65 904,5 мең сум;<br>2018 елда – 76 961,6 мең сум;<br>2019 елда – 58 578,6 мең сум;<br>II этап – Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 259 598,8 мең сум, шулардан:<br>2020 елда – 31 327,4 мең сум;<br>2021 елда – 84 274,1 мең сум;<br>2022 елда – 47 999,1 мең сум;<br>2023 елда – 47 999,1 мең сум;<br>2024 елда – 47 999,1 мең сум.<br>*Программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, Татарстан Республикасы бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш»; |

«Еллар буенча бүлеп, 1 нче ярдәмче программаның максатын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм аның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар буенча бүлеп, 1 нче ярдәмче программаның максатын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм аның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | 1 нче ярдәмче программаны тормышка ашыру түбәндәгеләргә мөмкинлек бирәчәк:<br>I этап (2014 – 2019 еллар):<br>2014 елга:<br>җирлекләрне яшелләндерү дәрәҗәсен 27 процентка кадәр арттырырга;<br>II этап (2020 – 2024 еллар):<br>2021 елга:<br>атмосфера һавасы пычрануның җыелма исәп-хисапларына кертелгән Татарстан Республикасының эре шәһәрләре санын 6га кадәр арттырырга;<br>2024 елга:<br>әйләнә-тирә мохит торышын күзәтүнең территориаль системасы урнаштырылган муниципаль районнар (шәһәр округлары) санын 40ка кадәр арттырырга;<br>әйләнә-тирә мохит сыйфаты буенча эшләнгән һәм гамәлгә кертелгән төбәк нормативлары санын 40 берәмлеккә кадәр арттырырга;<br>әйләнә-тирә мохитнең торышы, аның пычрануы белән бәйле тискәре күренешләр (тенденцияләр) турындагы фаразлар һәм кисәтүләрнең расланганлыгы өлешен 93 – 95 процентка кадәр тәэмин итәргә; |

| | |
|---|---|
| | «Татарстан Республикасының экологик картасы» дәүләт мәгълүмат системасының һәркем өчен файдалану мөмкинлеге булган ярдәмче системалары өлешен аларның гомуми саныннан 50 процентка кадәр арттырырга;<br>республикада халкының гомуми саныннан табигатьне саклау, экологик-агарту чараларында катнашучы халык өлешен 35,4 процентка кадәр арттырырга;<br>басма, электрон массакүләм мәгълүмат чараларында урнаштырылган һәм шәһәр, республика каналларында трансляцияләнә торган экологик тематика буенча максатчан мәгълүмат материаллары санын 945 данәгә кадәр арттырырга»; |

1 нче ярдәмче программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. 1 нче ярдәмче программаның
ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

1 нче ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 823 118,4 мең сум* тәшкил итәчәк, шул исәптән:

(мең сум)

| Ел | Барлык акча | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы |
|---|---|---|
| 2014 | 240 035,3 | 240 035,3 |
| 2015 | 53 741,1 | 53 741,1 |
| 2016 | 68 298,5 | 68 298,5 |
| 2017 | 65 904,5 | 65 904,5 |
| 2018 | 76 961,6 | 76 961,6 |
| 2019 | 58 578,6 | 58 578,6 |
| Барысы I этап | 563 519,6 | 563 519,6 |
| 2020 | 31 327,4 | 31 327,4 |
| 2021 | 84 274,1 | 84 274,1 |
| 2022 | 47 999,1 | 47 999,1 |
| 2023 | 47 999,1 | 47 999,1 |
| 2024 | 47 999,1 | 47 999,1 |
| Барысы II этап | 259 598,8 | 259 598,8 |
| Барлыгы | 823 118,4 | 823 118,4 |

*Финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, тиешле бюджетларның мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.»;

1 нче ярдәмче программага 2 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

«Татарстан Республикасында җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү өлкәсендә дәүләт идарәсе» ярдәмче программасында (алга таба – 2 нче ярдәмче программа):

2 нче ярдәмче программа паспортында:

«Еллар буенча бүлеп, 2 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr>
<td>«Еллар буенча бүлеп, 2 нче ярдәмче програм-маны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары</td>
<td>2 нче ярдәмче программаны тормышка ашыруны финанслар белән тәэмин итү күләме 2 984 016,1 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән 1 180 538,3 мең сумы – Татарстан Республикасы бюджеты акчасы, 1 803 477,8 мең сумы – билгеләнгән тәртиптә бүлеп бирелә торган федераль бюджет акчасы, шул исәптән:<br>
(мең сум)
<table>
<tr><th>ел</th><th>Барлыгы*</th><th>Федераль бюджет акчасы</th><th>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы</th></tr>
<tr><td>2014</td><td>164 187,8</td><td>-</td><td>164 187,8</td></tr>
<tr><td>2015</td><td>128 940,8</td><td>-</td><td>128 940,8</td></tr>
<tr><td>2016</td><td>26 902,2</td><td>-</td><td>26 902,2</td></tr>
<tr><td>2017</td><td>91 627,5</td><td>26 866,0</td><td>64 761,5</td></tr>
<tr><td>2018</td><td>91 059,8</td><td>-</td><td>91 059,8</td></tr>
<tr><td>2019</td><td>12 335,8</td><td>-</td><td>12 335,8</td></tr>
<tr><td>Барысы I этап</td><td>515 053,9</td><td>26 866,0</td><td>488 187,9</td></tr>
<tr><td>2020</td><td>1 113 805,9</td><td>718 084,2</td><td>395 721,7</td></tr>
<tr><td>2021</td><td>153 390,8</td><td>85 097,6</td><td>68 293,2</td></tr>
<tr><td>2022</td><td>484 419,8</td><td>392 380,0</td><td>92 039,8</td></tr>
<tr><td>2023</td><td>717 345,7</td><td>581 050,0</td><td>136 295,7</td></tr>
<tr><td>2024</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>Барысы II этап</td><td>2 468 962,2</td><td>1 776 611,8</td><td>692 350,4</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>2 984 016,1</td><td>1 803 477,8</td><td>1 180 538,3</td></tr>
</table>
*Финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, тиешле бюджетларның мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш»;</td>
</tr>
</table>

«Еллар буенча бүлеп, 2 нче ярдәмче программаның максатын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм аның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар буенча бүлеп, 2 нче ярдәмче программаның мак-сатын һәм бурыч- | Программа чараларын тулы күләмдә гамәлгә ашыру түбәндәгеләргә мөмкинлек бирәчәк:<br>I этап (2014 – 2019 еллар):<br>2016 елга: |

| | |
|---|---|
| ларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм аның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | каты коммуналь калдыкларның санкцияләнмәгән һәм бетерелгән чүплекләре өлешен 95 процентка кадәр арттырырга;<br>Татарстан Республикасы территориясендәге Куйбышев һәм Түбән Кама сусаклагычлары акваторияләре чикләрендә суга баткан 90 йөзү чарасын тикшерергә;<br>2019 елга:<br>тупланган әйләнә-тирә мохиткә зыянның 3 объектын бетерергә;<br>II этап (2020 – 2024 еллар):<br>2020 елга:<br>«Чиста ил» федераль проектын тормышка ашыру кысаларында тупланган экологик зыянның 2 аеруча куркыныч объектын бетерергә;<br>2021 елга:<br>«Чиста ил» федераль проектын тормышка ашыру кысаларында шәһәр чикләрендә 2 санкцияләнмәгән чүплекне бетерергә;<br>2024 елга:<br>барлыкка килгән каты коммуналь калдыкларның гомуми массасында күмү өчен җибәрелгән, шул исәптән эшкәртелгән (сортларга аерылган) каты коммуналь калдыклар өлешен 99,1 процентка кадәр арттырырга;<br>барлыкка килгән каты коммуналь калдыкларның гомуми массасында эшкәртүгә (сортларга аеруга) җибәрелгән каты коммуналь калдыклар өлешен 21 процентка кадәр арттырырга;<br>барлыкка килгән каты коммуналь калдыкларның гомуми массасында каты коммуналь калдыкларны аерып җыю һәм эшкәртү (сортларга аеру) нәтиҗәсендә аерылган һәм утилизацияләүгә җибәрелгән калдыклар өлешен 0,9 процентка кадәр арттырырга;<br>каты коммуналь калдыкларны аерым җыюны гамәлгә ашыру өчен җиһазландырылган контейнер мәйданчыклары өлешен 40 процентка кадәр арттырырга;<br>каты коммуналь калдыкларны заманча күмү объектларында урнаштырылган каты коммуналь калдыклар өлешен 100 процентка кадәр арттырырга;<br>үткәндәге экологик зыянның Идел елгасына куркыныч яный торган 2 объектын бетерергә»; |

2 нче ярдәмче программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. 2 нче ярдәмче программаның
ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

2 нче ярдәмче программаны тормышка ашыруны финанслар белән тәэмин итү күләме 2 984 016,1 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән 1 180 538,3 мең сумы – Татарстан Республикасы бюджеты акчасы, 1 803 477,8 мең сумы – билгеләнгән тәртиптә бүлеп бирелә торган федераль бюджет акчасы, шул исәптән:

(мең сум)

| Ел | Барлыгы* | Федераль бюджет акчасы | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы |
|---|---|---|---|
| 2014 | 164 187,8 | - | 164 187,8 |
| 2015 | 128 940,8 | - | 128 940,8 |
| 2016 | 26 902,2 | - | 26 902,2 |
| 2017 | 91 627,5 | 26 866,0 | 64 761,5 |
| 2018 | 91 059,8 | - | 91 059,8 |
| 2019 | 12 335,8 | - | 12 335,8 |
| Барысы I этап | 515 053,9 | 26 866,0 | 488 187,9 |
| 2020 | 1 113 805,9 | 718 084,2 | 395 721,7 |
| 2021 | 153 390,8 | 85 097,6 | 68 293,2 |
| 2022 | 484 419,8 | 392 380,0 | 92 039,8 |
| 2023 | 717 345,7 | 581 050,0 | 136 295,7 |
| 2024 | - | - | - |
| Барысы II этап | 2 468 962,2 | 1 776 611,8 | 692 350,4 |
| Барлыгы | 2 984 016,1 | 1 803 477,8 | 1 180 538,3»; |

*Финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, тиешле бюджетларның мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.»;

2 нче ярдәмче программага 2 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

«Татарстан Республикасының җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә дәүләт идарәсе» ярдәмче программасында (алга таба – 3 нче ярдәмче программа):

3 нче ярдәмче программа паспортында:

«Еллар буенча бүлеп, 3 нче ярдәмче программаны финанслау күләме» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар буенча бүлеп, 3 нче ярдәмче программаны финанслау күләме | 3 нче ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 533 044,6 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>I этап – Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 265 857,2 мең сум, шулардан:<br>2014 елда – 50 000,0 мең сум;<br>2015 елда – 47 483,8 мең сум;<br>2016 елда – 40 541,4 мең сум;<br>2017 елда – 42 332,0 мең сум; |

| | |
|---|---|
| | 2018 елда – 37 500,0 мең сум;<br>2019 елда – 48 000,0 мең сум;<br>II этап – Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 267 187,4 мең сум, шулардан:<br>2020 елда – 45 403,6 мең сум;<br>2021 елда – 71 783,8 мең сум;<br>2022 елда – 50 000,0 мең сум;<br>2023 елда – 50 000,0 мең сум;<br>2024 елда – 50 000,0 мең сум»; |

3 нче ярдәмче программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. 3 нче ярдәмче программаның
ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

3 нче ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 533 044,6 мең сум* тәшкил итәчәк.

(мең сум)

| Ел | Барлык акча | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы |
|---|---|---|
| 2014 | 50 000,0 | 50 000,0 |
| 2015 | 47 483,8 | 47 483,8 |
| 2016 | 40 541,4 | 40 541,4 |
| 2017 | 42 332,0 | 42 332,0 |
| 2018 | 37 500,0 | 37 500,0 |
| 2019 | 48 000,0 | 48 000,0 |
| I этап | 265 857,2 | 265857,2 |
| 2020 | 45 403,6 | 45 403,6 |
| 2021 | 71 783,8 | 71 783,8 |
| 2022 | 50 000,0 | 50 000,0 |
| 2023 | 50 000,0 | 50 000,0 |
| 2024 | 50 000,0 | 50 000,0 |
| II этап | 267 187,4 | 267 187,4 |
| Барысы | 533 044,6 | 533 044,6»; |

3 нче ярдәмче программага 2 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

«Татарстан Республикасының су хуҗалыгы комплексын үстерү» ярдәмче программасында (алга таба – 4 нче ярдәмче программа):

4 нче ярдәмче программа паспортында:

«Еллар буенча бүлеп, 4 нче ярдәмче программаны финанслау күләме» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr>
<td>«Еллар буенча бүлеп, 4 нче ярдәмче программаны финанслау күләме</td>
<td>4 нче ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 4 851 185,5 мең* сум тәшкил итәчәк, шул исәптән 1 643 675,1 мең сумы – билгеләнгән тәртиптә бүлеп бирелә торган федераль бюджет акчасы, 3 207 510,4 мең сумы – Татарстан Республикасы бюджеты акчасы, шул исәптән:<br>
(мең сум)
<table>
<tr><th>Ел</th><th>Барлык акча</th><th>Федераль бюджет акчасы</th><th>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы</th></tr>
<tr><td>2014</td><td>599 184,9</td><td>90 812,1</td><td>508 372,8</td></tr>
<tr><td>2015</td><td>153 356,8</td><td>58 429,0</td><td>94 927,8</td></tr>
<tr><td>2016</td><td>187 234,0</td><td>71 121,0</td><td>116 113,0</td></tr>
<tr><td>2017</td><td>1 013 376,8</td><td>302 908,9</td><td>710 467,9</td></tr>
<tr><td>2018</td><td>236 023,5</td><td>50 494,7</td><td>185 528,8</td></tr>
<tr><td>2019</td><td>546 178,7</td><td>77 040,3</td><td>469 138,4</td></tr>
<tr><td>I этап</td><td>2 735 354,6</td><td>650 805,9</td><td>2 084 548,7</td></tr>
<tr><td>2020</td><td>1 495 876,4</td><td>608 268,4</td><td>887 608,0</td></tr>
<tr><td>2021</td><td>289 890,4</td><td>80 046,7</td><td>209 843,7</td></tr>
<tr><td>2022</td><td>169 759,8</td><td>153 153,6</td><td>16 606,2</td></tr>
<tr><td>2023</td><td>135 893,5</td><td>126 989,7</td><td>8 903,8</td></tr>
<tr><td>2024</td><td>24 410,8</td><td>24 410,8</td><td>0,0</td></tr>
<tr><td>II этап</td><td>2 115 830,9</td><td>992 869,2</td><td>1 122 961,7</td></tr>
<tr><td>Барысы</td><td>4 851 185,5</td><td>1 643 675,1</td><td>3 207 510,4</td></tr>
</table>
*Финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, тиешле бюджетларның мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш»;</td>
</tr>
</table>

«Еллар буенча бүлеп, 4 нче ярдәмче программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм аның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr>
<td>«Еллар буенча бүлеп, 4 нче ярдәмче программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәти-</td>
<td>4 нче ярдәмче программаны тормышка ашыру түбәндәгеләргә мөмкинлек бирәчәк:<br>
2020 елга:<br>
судан файдалануны гамәлгә ашыру су объектларыннан файдалану хокукларын сатып алуны күздә тота торган судан файдаланучыларның гомуми санында билгеләнгән тәртиптә бирелгән файдалану хокуклары нигезендә су объектларыннан файдалануны гамәлгә ашыручы судан файдаланучылар өлешен 99 процентка кадәр арттырырга;</td>
</tr>
</table>

| | |
|---|---|
| җәләрне бәяләү индикаторлары) һәм аның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | су объектларын торгызу һәм экологик тернәкләндерү чараларын тормышка ашыру нәтиҗәсендә экологик яшәү шартлары яхшыртылачак халык санын 267,3 мең кешегә арттырырга;<br>су алу корылмаларының гомуми санында суны исәпкә алу системалары белән җиһазландырылган су алу корылмалары өлешен 96 процентка кадәр арттырырга;<br>су объектларын торгызу һәм экологик тернәкләндерү эшләре озынлыгын 49,7 километрга кадәр арттырырга;<br>су объектларын торгызу һәм экологик тернәкләндерү эшләре мәйданын 1 042,89 мең кв.метрга кадәр арттырырга;<br>2022 елга:<br>яңа реконструкцияләнгән инженерлык саклау һәм яр буен ныгыту корылмаларының озынлыгын 21,32 километрга кадәр арттырырга;<br>су объектларын торгызу һәм экологик тернәкләндерү чараларын тормышка ашыру нәтиҗәсендә экологик яшәү шартлары яхшыртылачак халык санын 267,4 мең кешегә арттырырга;<br>2023 елга:<br>суларның тискәре йогынтысына дучар булган территорияләрдә яшәүче халыкның гомуми санында суларның тискәре йогынтысыннан сакланышны арттыру чараларын үткәрү нәтиҗәсендә сакланган, суларның тискәре йогынтысына дучар булган территорияләрдә яшәүче халыкның өлешен 80,6 процентка кадәр арттырырга;<br>куркынычсызлыгы канәгатьләндермәгән һәм куркынычсызлык дәрәҗәсе куркыныч булган 94 гидротехника корылмасын имин техник хәлгә китерергә;<br>куркынычсызлыгы канәгатьләндермәгән һәм куркынычсызлык дәрәҗәсе куркыныч булган гидротехника корылмаларының гомуми санында куркынычсызлык дәрәҗәсе канәгатьләнерлек булмаган һәм куркыныч булган, имин техник хәлгә китерелгән гидротехника корылмалары өлешен 71 процентка кадәр арттырырга;<br>«Уникаль су объектларын саклау» федераль проектын тормышка ашыру кысаларында елгалар үзәннәренең чистартылган участоклары озынлыгын 13,3 километрга кадәр тәэмин итәргә;<br>су объектларының яр буе полосасын 4 мең километр чистарту акциясендә 220 меңнән артык кешене җәлеп итәргә»; |

4 нче ярдәмче программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. 4 нче ярдәмче программаның
ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

4 нче ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 4 851 185,5 мең* сум тәшкил итәчәк, шул исәптән 1 643 675,1 мең сумы – билгеләнгән тәртиптә бүлеп бирелә торган федераль бюджет акчасы, 3 207 510,4 мең сумы – Татарстан Республикасы бюджеты акчасы, шул исәптән:

(мең сум)

| Ел | Барлык акча | Федераль бюджет акчасы | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 2014 | 599 184,9 | 90 812,1 | 508 372,8 |
| 2015 | 153 356,8 | 58 429,0 | 94 927,8 |
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 2016 | 187 234,0 | 71 121,0 | 116 113,0 |
| 2017 | 1 013 376,8 | 302 908,9 | 710 467,9 |
| 2018 | 236 023,5 | 50 494,7 | 185 528,8 |
| 2019 | 546 178,7 | 77 040,3 | 469 138,4 |
| I этап | 2 735 354,6 | 650 805,9 | 2 084 548,7 |
| 2020 | 1 495 876,4 | 608 268,4 | 887 608,0 |
| 2021 | 289 890,4 | 80 046,7 | 209 843,7 |
| 2022 | 169 759,8 | 153 153,6 | 16 606,2 |
| 2023 | 135 893,5 | 126 989,7 | 8 903,8 |
| 2024 | 24 410,8 | 24 410,8 | 0,0 |
| II этап | 2 115 830,9 | 992 869,2 | 1 122 961,7 |
| Барысы | 4 851 185,5 | 1 643 675,1 | 3 207 510,4 |

*Финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, тиешле бюджетларның мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.»;

4 нче ярдәмче программага 2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

«Татарстан Республикасының биологик төрлелеген саклау» ярдәмче программасында (алга таба – 5 нче ярдәмче программа):

5 нче ярдәмче программа паспортында:

«Еллар буенча бүлеп, 5 нче ярдәмче программаны финанслау күләме» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар буенча бүлеп, 5 нче ярдәмче программаны финанслау күләме | 5 нче ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 370 207,1 мең сум* тәшкил итәчәк, шул исәптән:<br>I этап – Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 171 735,5 мең сум, шулардан:<br>2014 елда – 24 648,6 мең сум; |

| | |
|---|---|
| | 2015 елда – 23 958,4 мең сум;<br>2016 елда – 23 992,7 мең сум;<br>2017 елда – 21 767,8 мең сум;<br>2018 елда – 43 114,6 мең сум;<br>2019 елда – 34 253,4 мең сум;<br>II этап – Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 198 471,6 мең сум, шулардан:<br>2020 елда – 44 534,3 мең сум;<br>2021 елда – 38 457,9 мең сум;<br>2022 елда – 38 478,8 мең сум;<br>2023 елда – 38 500,3 мең сум;<br>2024 елда – 38 500,3 мең сум.<br>*Программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, Татарстан Республикасы бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш»; |

«Еллар буенча бүлеп, 5 нче ярдәмче программаның максатын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм аның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар буенча бүлеп, 5 нче ярдәмче программаның максатын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм аның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | 5 нче ярдәмче программаны тормышка ашыру түбәндәгеләргә мөмкинлек бирәчәк:<br>2014 – 2019 елларда:<br>Татарстан Республикасының Кызыл китабына ел саен кертелгән, сирәк булуның иң түбән категориясенә күчерелгән төрләр санын 1 берәмлек дәрәҗәсендә сакларга;<br>Татарстан Республикасының Кызыл китабына ел саен кертелгән төрләр санын 1 берәмлек дәрәҗәсендә сакларга;<br>ел саен Татарстан Республикасының Кызыл китабыннан 1 төрне чыгарырга;<br>2024 елга:<br>Татарстан Республикасының гомуми мәйданында барлык дәрәҗәләрдәге махсус саклана торган табигать территорияләре биләгән Татарстан Республикасы мәйданы өлешен 6,8 процентка кадәр арттырырга;<br>төбәк һәм җирле әһәмияттәге махсус саклана торган табигать территорияләре биләгән Татарстан Республикасы мәйданы өлешен 6,3 процентка кадәр арттырырга;<br>Татарстан Республикасының махсус саклана торган табигать территорияләрендә ачыкланган һәм кисәтелгән бозулар санын 690 берәмлеккә кадәр арттырырга;<br>ел саен хайваннар, үсемлекләр һәм гөмбәләрнең сирәк булган һәм юкка чыгу куркынычы янаган төрләре очрауның |

| | |
|---|---|
| | тутырылган карточкалары санын кимендә 2 100 берәмлек тәэмин итәргә;<br>махсус саклана торган табигать территорияләрендә ачыкланган һәм кисәтелгән бозулар санын 690 берәмлеккә кадәр арттырырга;<br>махсус саклана торган табигать территорияләре мәсьәләләре буенча лекцияләргә һәм башка гавами чараларга җәлеп ителгән укучылар санын 23,6 мең кешегә кадәр арттырырга»; |

5 нче ярдәмче программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. 5 нче ярдәмче программаның
ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

5 нче ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 370 207,1 мең сум* тәшкил итәчәк, шул исәптән:

I этап – Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 171 735,5 мең сум, шулардан:

2014 елда – 24 648,6 мең сум;
2015 елда – 23 958,4 мең сум;
2016 елда – 23 992,7 мең сум;
2017 елда – 21 767,8 мең сум;
2018 елда – 43 114,6 мең сум;
2019 елда – 34 253,4 мең сум;

II этап – Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 198 471,6 мең сум, шулардан:

2020 елда – 44 534,3 мең сум;
2021 елда – 38 457,9 мең сум;
2022 елда – 38 478,8 мең сум;
2023 елда – 38 500,3 мең сум;
2024 елда – 38 500,3 мең сум.

*Финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, Татарстан Республикасы бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.»;

5 нче ярдәмче программага 2 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

«Татарстан Республикасының аучылык ресурсларын торгызу һәм алардан файдалану» ярдәмче программасында (алга таба – 6 нчы ярдәмче программа):

6 нчы ярдәмче программа паспортында:

«Еллар буенча бүлеп, 6 нчы ярдәмче программаны финанслау күләме» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr>
<td>«Еллар буенча бүлеп, 6 нчы ярдәмче программаны финанслау күләме</td>
<td>6 нчы ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 672 648,6 мең сум* тәшкил итәчәк, шул исәптән 215 614,2 мең сумы – билгеләнгән тәртиптә бүлеп бирелә торган федераль бюджет акчасы, 457 034,4 мең сумы – Татарстан Республикасы бюджеты акчасы, шул исәптән:<br><br>(мең сум)
<table>
<tr><th>Ел</th><th>Барлыгы</th><th>Федераль бюджет акчасы</th><th>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы</th></tr>
<tr><td>2014</td><td>63 899,9</td><td>18 298,1</td><td>45 601,8</td></tr>
<tr><td>2015</td><td>40 072,4</td><td>14 396,8</td><td>25 675,6</td></tr>
<tr><td>2016</td><td>51 759,1</td><td>18 161,5</td><td>33 597,6</td></tr>
<tr><td>2017</td><td>52 444,0</td><td>19 098,3</td><td>33 345,7</td></tr>
<tr><td>2018</td><td>67 675,4</td><td>19 540,7</td><td>48 134,7</td></tr>
<tr><td>2019</td><td>74 127,3</td><td>20 070,1</td><td>54 057,2</td></tr>
<tr><td>I этап</td><td>349 978,1</td><td>109 565,5</td><td>240 412,6</td></tr>
<tr><td>2020</td><td>77 225,0</td><td>20 659,4</td><td>56 565,6</td></tr>
<tr><td>2021</td><td>61 251,2</td><td>21 284,7</td><td>39 966,5</td></tr>
<tr><td>2022</td><td>61 433,7</td><td>21 429,8</td><td>40 003,9</td></tr>
<tr><td>2023</td><td>61 380,3</td><td>21 337,4</td><td>40 042,9</td></tr>
<tr><td>2024</td><td>61 380,3</td><td>21 337,4</td><td>40 042,9</td></tr>
<tr><td>II этап</td><td>322 670,5</td><td>106 048,7</td><td>216 621,8</td></tr>
<tr><td>Барысы</td><td>672 648,6</td><td>215 614,2</td><td>457 034,4</td></tr>
</table>
*Финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, тиешле бюджетларның мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш»;</td>
</tr>
</table>

6 нчы ярдәмче программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. 6 нчы ярдәмче программаның
ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

6 нчы ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 672 648,6 мең сум* тәшкил итәчәк, шул исәптән 215 614,2 мең сумы – билгеләнгән тәртиптә бүлеп бирелә торган федераль бюджет акчасы, 457 034,4 мең сумы – Татарстан Республикасы бюджеты акчасы, шул исәптән:

(мең сум)

| Ел | Барлыгы | Федераль бюджет акчасы | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы |
|---|---|---|---|
| 2014 | 63 899,9 | 18 298,1 | 45 601,8 |
| 2015 | 40 072,4 | 14 396,8 | 25 675,6 |
| 2016 | 51 759,1 | 18 161,5 | 33 597,6 |
| 2017 | 52 444,0 | 19 098,3 | 33 345,7 |
| 2018 | 67 675,4 | 19 540,7 | 48 134,7 |
| 2019 | 74 127,3 | 20 070,1 | 54 057,2 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| I этап | 349 978,1 | 109 565,5 | 240 412,6 |
| 2020 | 77 225,0 | 20 659,4 | 56 565,6 |
| 2021 | 61 251,2 | 21 284,7 | 39 966,5 |
| 2022 | 61 433,7 | 21 429,8 | 40 003,9 |
| 2023 | 61 380,3 | 21 337,4 | 40 042,9 |
| 2024 | 61 380,3 | 21 337,4 | 40 042,9 |
| II этап | 322 670,5 | 106 048,7 | 216 621,8 |
| Барысы | 672 648,6 | 215 614,2 | 457 034,4 |

*Финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, тиешле бюджетларның мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.»;

6 нчы ярдәмче программага 2 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

«Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитен саклау һәм табигатьтән файдалану өлкәсендә хезмәтләр эшчәнлеген координацияләү» ярдәмче программасында (алга таба – 7 нче ярдәмче программа):

7 нче ярдәмче программа паспортында:

«Еллар буенча бүлеп, 7 нче ярдәмче программаны финанслау күләме» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар буенча бүлеп, 7 нче ярдәмче программаны финанслау күләме | 7 нче ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 2 622 791,7 мең сум* тәшкил итәчәк, шул исәптән:<br>I этап – Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 1 449 501,4 мең сум, шулардан:<br>2014 елда – 183 317,7 мең сум;<br>2015 елда – 232 804,6 мең сум;<br>2016 елда – 229 556,8 мең сум;<br>2017 елда – 250 609,3 мең сум;<br>2018 елда – 259 938,2 мең сум;<br>2019 елда – 293 274,8 мең сум;<br>II этап – Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 1 173 290,3 мең сум, шулардан:<br>2020 елда – 291 573,7 мең сум;<br>2021 елда – 219 863,1 мең сум;<br>2022 елда – 220 308,7 мең сум;<br>2023 елда – 220 772,4 мең сум;<br>2024 елда – 220 772,4 мең сум.<br>*Программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, Татарстан Республикасы бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш»; |

«Еллар буенча бүлеп, 7 нче ярдәмче программаның максатын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү

индикаторлары) һәм аның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар буенча бүлеп, 7 нче ярдәмче программаның максатын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм аның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | 7 нче ярдәмче программаны тормышка ашыру түбәндәгеләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>I этап (2014 – 2019 еллар):<br>2018 елга:<br>төбәк дәүләт экология күзәтчелеге нәтиҗәлелеген 3,8 мең сум күләмендә тәэмин итәргә;<br>2019 елга:<br>тышкы мохитнең (су, һава һәм туфрак) сайлап алынган пробалары санын 35 160 данәгә кадәр арттырырга;<br>тышкы мохитнең (су, һава һәм туфрак) сайлап алынган пробаларына үткәрелгән лаборатория анализлары санын 64 460 данәгә кадәр арттырырга;<br>2018 – 2019 елларга Россия Федерациясе субъектларында Инвестицион климат торышының илкүләм рейтингы күрсәткечләре нигезендә Татарстан Республикасында инвестицион климатны яхшырту чаралары планының («юл картасының») билгеләнгән вакытларда үтәлгән чаралары өлешен 100 процент тәэмин итәргә;<br>II этап (2020 – 2024 еллар):<br>2022 елга:<br>җитештерү һәм куллану калдыкларын санкцияләнмәгән урнаштыру аркасында пычранган җир кишәрлекләренең гомуми мәйданыннан төзекләндерелгән җир кишәрлекләре өлешен 96 процентка кадәр тәэмин итәргә;<br>2024 елга:<br>әйләнә-тирә мохитнең сыйфатын 108,45 процент дәрәҗәсендә тәэмин итәргә;<br>хуҗалык һәм башка эшчәнлекне, территория планын эшләүне һәм дәүләт экология экспертизасын үткәрүне планлаштырганда әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә теркәлгән мөрәҗәгатьләр санының әзерләнгән килештерүләр һәм үткәрелгән дәүләт экологик экспертизасы саны белән нисбәтен 100 процент дәрәҗәсендә тәэмин итәргә;<br>стационар чыганаклардан чыга торган пычраткыч матдәләрнең гомуми күләмендә тотылган һәм зарарсызландырылган пычраткыч атмосфера һавасы матдәләре өлешен 61 процентка кадәр арттырырга;<br>тикшерелгән автомобильләрнең гомуми санында эшләп чыгарылган газларында пычраткыч матдәләр артык күп булган автотранспорт чаралары өлешен 6,8 процентка кадәр киметергә;<br>су чыгаруның гомуми күләмендә пычрак (чистартылмаган) агып |

| | |
|---|---|
| | төшә торган сулар өлешен 11,1 процентка кадәр киметергә;<br>рекультивацияләнә торган җирләр өлешен 46 процентка кадәр арттырырга;<br>табигатьтән файдалану һәм әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә ачыкланган бозулар арасыннан бетерелгән бозулар өлешен (В.2.5 төркеме күрсәткече) кимендә 96 процент тәэмин итәргә;<br>салынган штрафлардан түләтелгән акча өлешен (В.3.1.37 төркеме күрсәткече) кимендә 70 процент тәэмин итәргә;<br>«Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына кергән «Гариза хәл ителде» статусы бирелгән гаризалар өлешен кимендә 50 процент тәэмин итәргә;<br>«Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасында «Гариза хәл ителде» статусы бирелгән һәм «Вакытында үтәлмәде» статусы билгеләнгән хәбәрнамәләрнең булмавын тәэмин итәргә;<br>әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә мәҗбүри таләпләр буенча ачыкланган бозулар санын (В.3.2.2 төркеме күрсәткече) 3 357 берәмлеккә кадәр киметергә;<br>административ җәзаларның гомуми санында кисәтүләр өлешен кимендә 10 процентка арттырырга;<br>төбәк дәүләт экология күзәтчелеген, мониторингны һәм табигатьне саклау буенча башка чараларны тормышка ашырганда сайлап алу өчен алынган пробаларның гомуми санына карата тикшерелгән пробалар санының нисбәтен 100 процент тәэмин итәргә;<br>эзләү-тикшерү максаты белән нефть скважиналарын бораулауның планлаштырылган күләменә карата аның факттагы күләме нисбәтен 100 процентка кадәр тәэмин итәргә;<br>геологик разведка эшләре нәтиҗәләре турындагы хисаплар саны һәм үткәрелгән дәүләт экспертизалары саны нисбәтен 100 процентка кадәр тәэмин итәргә;<br>мөрәҗәгатьләрнең гомуми санында геологик мәгълүмат бирү турындагы канәгатьләндерелгән заявкалар санын 99 процентка кадәр арттырырга;<br>бирелгән лицензияләр санының файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, разведкалау һәм чыгару максаты белән җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын алу өчен карап тикшерелгән гаризалар санына карата нисбәтен 96 процентка кадәр арттырырга;<br>Татарстан Республикасының гомумтаралган файдалы казылмалар запасларының еллык расланган балансын 1 баланс итеп тәэмин итәргә;<br>эзләү-тикшерү һәм эксплуатацияләү максаты белән нефть |

| | |
|---|---|
| | скважиналарын бораулауның планлаштырылган күләме үтәлешен 100 процентка кадәр тәэмин итәргә;<br>лицензиядә күрсәтеп үтелгән билгеле бер вакыйгалар килеп чыкканда, гомумтаралган файдалы казылмаларга ия булган җир асты кишәрлекләре яки җирле әһәмияттәге җир асты кишәрлекләре буенча Россия Федерациясе территориясендә җир асты байлыкларыннан файдаланганда җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен Татарстан Республикасы бюджетына бер тапкыр түләнә торган түләүләр керүне 100 процентка кадәр тәэмин итәргә;<br>административ регламентлары расланган әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә дәүләт хезмәте күрсәтүләр һәм табигатьтән файдалану өлкәсендә контрольдә тоту (күзәтчелек итү) буенча дәүләт функцияләре өлешен Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы тарафыннан күрсәтелә торган әлеге дәүләт хезмәте күрсәтүләрнең (дәүләт функцияләренең) гомуми санында 100 процент дәрәҗәсендә сакларга;<br>йөкләмәләрнең гомуми күләмендә Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Премьер-министры, Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарлары йөкләмәләренең билгеләнгән контроль вакытларда 100 процент үтәлешен тәэмин итәргә;<br>Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы тарафыннан шәхсиләштерелгән йөкләмәләрнең, шул исәптән «Ачык Татарстан» системасында үз вакытында яңартылган хисапларның һәм «Илкүләм проектларын контрольдә тоту» юнәлеше буенча Татарстан Республикасының мәгълүмат-аналитика системасына җавап бирә торган төбәк проектлар буенча кертелгән мәгълүматларның 100 процент итеп үтәлүен тәэмин итәргә»;<br>Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгына кергән гражданнар мөрәҗәгатьләренең гомуми күләмендә әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән файдалану өлкәсендә гражданнарның аларга элек язма җаваплар бирелгән мәсьәләләрен үз эченә алган, кабат язылган мөрәҗәгатьләре өлешен 0 процент дәрәҗәсендә сакларга;<br>әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән файдалану өлкәсендә идарәгә дәүләт заказын 100 процент үтәүне тәэмин итәргә;<br>төзелгән контрактларның гомуми кыйммәтендә сатып алуларның барып чыкмаган конкурент ысуллары нәтиҗәләре |

| | |
|---|---|
| | буенча төзелгән контрактлар кыйммәте өлешен иң күбе 11 процент дәрәҗәсендә тәэмин итү»; |

7 нче ярдәмче программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. 7 нче ярдәмче программаның
ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

7 нче ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 2 622 791,7 мең сум* тәшкил итәчәк, шул исәптән:

I этап – Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 1 449 501,4 мең сум, шулардан:

2014 елда – 183 317,7 мең сум;
2015 елда – 232 804,6 мең сум;
2016 елда – 229 556,8 мең сум;
2017 елда – 250 609,3 мең сум;
2018 елда – 259 938,2 мең сум;
2019 елда – 293 274,8 мең сум;

II этап – Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 1 173 290,3 мең сум, шулардан:

2020 елда – 291 573,7 мең сум;
2021 елда – 219 863,1 мең сум;
2022 елда – 220 308,7 мең сум;
2023 елда – 220 772,4 мең сум;
2024 елда – 220 772,4 мең сум.

*Финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, Татарстан Республикасы бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.»;

7 нче ярдәмче программага 2 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин